КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче Югары Шытсу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

09.09.2022 № 3

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 27 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып 2022 елның 09 сентябрендә узган гражданнар җыенында «Сез 2023 нче елда Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче Югары Шытсу торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1150,00 (бер мең бер йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы»:

- ТР Саба муниципаль районы Югары Шытсу авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (грунтны эшләү, комнан, вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, сусүткәргеч торбаларны җиһазлау, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Күмү урыннарын карап тоту: ТР Саба муниципаль районының Югары Шытсу авылы зират территориясен коймалап алу (бетон нигезгә металл баганалар урнаштыру, металл өслекләрне буяу, коймалар урнаштыру (профиль, штакетник урнаштыру), килешү буенча эшләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 234 кеше кертелгән, җыенда һәм тавыш бирүдә катнашучылар саны 121 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 121 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче Югары Шытсу торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2023 нче елда Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче Елыш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1150,00 (бер мең бер йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) ТР Саба муниципаль районы Югары Шытсу авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (грунтны эшләү, комнан, вак таштан нигез салу,

юл читләрен урнаштыру, суүткәргеч торбаларны җиһазлау, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Күмү урыннарын карап тоту: ТР Саба муниципаль районының Югары Шытсу авылы зират территориясен коймалап алу (бетон нигезгә металл баганалар урнаштыру, металл өслекләрне буяу, коймалар урнаштыру (профиль, штакетник урнаштыру), килешү буенча эшләр өчен түләү), карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shitsi адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Түбән Шытсу авыл
җирлеге башлыгы Б.М.Мәүлетов